**Харис, Р. Төрек валы: поэма / Р. Харис // Мәдәни җомга. – 2020. – 21 февраль (№7). – Б. 7.**


Ренат ХАРИС

ТӨРЕК ВАЛЫ

«... Мең тугыз йөз кырык өчнең көзе...

«Перекоптан, Төрек валыннан

Фашистларны куып чыгарырга!...»

Дигән утлы боерык алына...

Геродотлар заманыннан бирле

Бүгенгәчә үзен аклаган

Хәрби ныгытмада кемнең генә

Кем куланнан каны акмаган?!

Монда римлы, скиф, төрек, урыс

Татар алган соңгы сулышын

Кырым бугазына ябырылып.

Шушы җирләр өчен сугышып... »

Бөек җиңүнең 75 еллыгын каршыларга әзерләнәбез. Шул уңайдан Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе һәм Россиянең дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис «Төрек валы» дип исемләнгән яңа поэмасын тәкъдим итә. Бу шигъри әсәр беренчеләрдән булып «Мәдәни җомга» газетасының 7нче санында басылып чыкты.